КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 11 ноябрь 990

«Төньяк капка» индустриаль (сәнәгать)
паркын төзү турында

Татарстан Республикасының сәнәгать инфраструктурасы объектлары үстерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә «Төньяк капка» индустриаль (сәнәгать) паркын төзү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Төзелеп килә торган «Төньяк капка» индустриаль (сәнәгать) паркының идарәче компаниясе сыйфатында «Төньяк капка» акционерлык җәмгыятен билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин